Идиәт Аширов
Урал аһәңнәре
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ә91

**Әширов И.М.**

Урал аһәңнәре: шигырьләр / Идият Әширов; кереш сүз авт. Рәшит Ягъфәров. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 96 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01599-8

Пермь өлкәсенең Барда районында яшәүче Идият Әширов шигырьләре туган як һәм аның кешеләрен ярату хисе белән сугарылган. Алар авторның язмышы һәм җәмгыяви эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә.

ISBN 978-5-298-01599-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Әширов И.М., 2007

## ҺИДАЯТЬЛЕ ИДИЯТ

Аның холык-фигыле шундый: көрешкән-сөйләшкән вакытларда ул, «бу кешенең бәгърендә берәр борчуы, гозере бар микән әллә?» дигән кебек, җанны үтәли тишеп, туп-туры йөзгә-күзгә карый һәм, берәр проблемаң барын белсә, шундук аны хәл итәр өчен йөгереп китәргә әзер тора. Ни кызганыч, хәзерге болгавыр һәм «кыргый» заманда андыйларны санлап бетермиләр. Кеше өчен җанын ярып бирергә әзер самими һәм карусыз затларга ай-һай яшәү авыр хәзер. Әмма җәмгыятьнең һәм халкыбызның әхлакый кануннары исән икән әле. Мондый затлар да, бик җиңел булмаса да, олы дәрәҗәләргә күтәрелә, халык ихтирамын казана ала икән. Бу хакыйкатьне йомшак табигатьле дустым һәм якташым шагыйрь Идият Әширов та үзенең 60 еллык гомере белән исбат итте.

Идият Пермь өлкәсе Барда районының Сөҗән дигән авылында туып үскән. Султанай һәм Батырбай мәктәпләрендә укыган.

Без аның белән Сараш урта мәктәбендә укыганда очрашып дуслаштык. Аннан Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыдык, интернат-тулай торакларда «чүлмәк үрәләре»н (лаеш шулпасын безнең якта шулай дип атыйлар) бергәләп чөмердек.

Шунысы гаҗәп: мәктәптә укыганда да, университетта да йомшак күңелле Идият һәрвакыт лидер булды. Университетта укыганда, Зиннур Мансуров, Нәҗибә Сафина, Рашат Низамиев, Әнвәр Хәйри, Риман Гыйлемханов кебек ажгырып торган егет-кызлар булган группада аны, артык итагатьле, йомшак табигатьле Идиятне, староста иттеләр.

Университетны тәмамлап кайткач, Барда районының Төнгүк авылында бераз укытучы булып эшләгән иде, аны Яңавыл мәктәбенә директор итеп җибәрделәр. Аннан соң («каты куллы» партия һәм совет эшлекләре мыжлап торган заманда бит!) авыл кешеләре аны, шигъри җанлы, нечкә күңелле, садә кешене, үзләренең авыл советы рәисе итеп сайладылар. Аннан халык аны район советы депутаты итте, соңыннан Идиятне район советына, район советы башкарма комитетына, район хакимиятенә җаваплы урыннарга күтәрделәр.

Аның күңелендә шигырь уты иртә кабынды. Әле бала чагында, Султанай мәктәбендә укыганда ук, ул каләм тибрәтә башлаган иде. Казан дәүләт университетын тәмамлап Бардага кайткач, ул актив иҗатка кереште, район газетасы каршындагы «Таң йолдызы» әдәби берләшмәсе белән җитәкчелек итте. Барда төбәгендә барган мәдәни һәм әдәби хәрәкәтнең башында булды. 1999 елда аның Барда китап нәшриятында «Гомер юллары» дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. 2000 елда Пермь өлкәсендә татар әдәбияты көннәре вакытында Бардада үткәрелгән Татарстан Язучылар берлегенең шигърият остаханәсе җыелышында аны Татарстанның Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим иттеләр, һәм ул тиздән аңа кабул да ителде.

Идияткә «коеп куйган шагыйрь» булып кына яшәргә насыйп булмады. Иҗаты, хөкүмәт-казна эше белән аралашып, еллар, төнге йокылар хисабына барды.

Шигырьләренең эчтәлегенә күз салсаң, аларның автор язмышы, аның җәмгыяви эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә икәнлеге ачык күренә. Аның әсәрләре туган як һәм аның кешеләрен ярату хисе белән сугарылган. Аларда авторның тулысынча якташларының гаме белән яшәве төсмерләнә. Хөкүмәт даирәләрендә эшләүче кеше буларак, ул җәмгыятьтәге һәм дәүләт сәясәтендә барган уңай һәм тискәре күренешләрне дә ачык сиземли һәм аларга шигърият теле белән мөнәсәбәтен белдерә.

Аның шигъриятендә юмористик мотивлар да чит-ят түгел. Тормыштагы халәте, шаяртып, «төрттереп» алырга яратуы шигырьләренә дә күчкән.

И.Әширов күп кенә җырлар авторы да. Аның композиторлар Луиза Батыр-Болгари, Сәүбән Чуганаевлар белән бергә иҗат иткән җырлары Пермь төбәгендә бик популяр.

…Идиятне кеше өчен җанын ярып бирергә әзер карусыз зат дигән идек. Халкыбызга, милләтебезгә карата да шулай, аның кайгысын кайгыртып йөгереп китәргә, утка-суга керергә дә әзер.

Менә шундый йомшак күңелле, кече җанлы, итагатьле, шигъри җанлы, һидаятьле Идият яши Бардада (һидаятьле — туры юлдан баручы дигәнне аңлата). Бу «йомшак» кешенең төбәктә абруе зур, мәдәнилектә, фидакарьлектә, әдәплелектә һәркемгә үрнәк булып, һәркемнең ихтирамын тоеп гомер итә ул.

Аның тормыш юлына карыйм да шуңа инанам, тоткан җирдән умырып алырдай «каты куллы» булмаса да, халкын-милләтен яратып, самимилек белән аның мәнфәгатен кайгыртып яшәсә, олы хөрмәткә ирешә ала икән адәм баласы. Идият нәкъ шундыйлардан.

Бу күркәм кешене 60 яше тулу уңае белән котлыйбыз һәм безне, укучыларын, яңа иҗат җимешләре белән куандыруын телибез.

*Рәшит Ягъфәров*

**БАРДА ҖИРЕ**

*(Җыр)*

Барда ягы — чал тарихлы төбәк,
Бабаларым каны тамган җир.
Батыршага куш(ы)лып, ирек даулап
Яу чапканнар күпме баһадир.

Барда җирем — гүзәл Гәйнә иле,
Әнкәй килен булып төшкән җир.
Халкым моңын көйләп, бәхет теләп
Әткәй иген иккән, түккән тир.

Кушымта:

Их! Безнең Барда!
Без бар да бергә.
Милли горурлыкны саклап
Яшик гомергә.
Их! Без бар да,
Без бар да бергә.
Бәхетебез тик туган җирдә.

Барда ягы — дусны, туганнарны
Очраштырган сабантуйлы җир.
Көрәш мәйданында, бәйгеләрдә
Бил алышмый түзәр нинди ир.

Барда җире — сибелгән халкымның
Телен, рухын саклап калган җир.
Яшәр өчен безгә мәңге бергә,
Әй, Ходаем, исәнлекләр бир!

Кушымта.

**БЕЗ КЕМ?**

Типтәрләр без — тибәрелгән халык.
Гәйнәләр без — Гәйнә илендә,
Таныклыкта — башкорт. Сөйләшәбез,
Аңлашабыз татар телендә.

«Тамырлары башкорт ыруыннан, —
Дип сөйлиләр, — безнең халыкның...»
Башкорт дисәң, күз алдына килә
Башкорт зыяраты Таныпның.

Кыйблабыз һәм рухи мәркәзебез
Татарстан элек-электән.
Гореф-гадәтебез, шәҗәрәбез
Тукай нәселе белән береккән.

Ә шулай да без кем? Телебез — татар.
«Башкорт», — диләр, ачып паспортны.
Башкорт канлы Барда татары без,
Татар җанлы Гәйнә башкорты.

**ГОРУРЛЫК**

*Районыбыз тарихына багышланган «Гәйнә иле» китабы авторы Әмир ага Фатыйховка*

Бәхәс бара, белмим, күпме еллар:
«Кем дәвамы монда? Ни халык?»
Җавап эзлим бүген шушы хакта,
Синең язганнарга тукталып.

Арта бара көчем, укыган саен
Туа җанда үзгә горурлык.
Һәр бүлеге олы хезмәтеңнең
Кыйсса, дастаннарга торырлык.

Бар икән шул горурланыр форсат,
Сокланырлык икән үткәннәр.
Бабаларым килмешәкләр түгел,
Монда туып, монда үскәннәр.

Икмәк үстергәннәр урман арчып,
Дошман килсә, яуга чыкканнар,
Җиде газизләрең җиде җирдә
Хәбәр биреп учак якканнар.

Авырлыклар көн дә очрап торган,
Еш түгелгән кеше каннары.
Ширәмәтнең бакыр базлары да
Сыкраткандыр күпме җаннарны.

Башкорт дип тә, татар дип тә безне
Исбатлаулар, дөрес, җитәрлек.
«Ник урыс түгел?» дип әйтүләр бар.
Уйлый китсәң, исең китәрлек.

Кысу, эзәрлекләү, кимсетүдән
Бетмәгәнбез, шөкер, тапланып.
Заман җилләренә бирешмичә,
Тарихыбыз калган сакланып.

Китабыңны укыйм... горурланып
Искә алам синең исемне —
Онытыла язган тарихыма
Яшәү биргән галим кешене.

## БАРДА БЕЛӘН АРЧА АРАСЫ

Барда белән Арча арасы...
Ничә чакрым икән барасы?
Очрашсыннар, сөйләшсеннәр әле
Бер милләтнең ике баласы.

Барда белән Арча арасы...
Кардәшлекне искә аласы:
Тукай булса Арча җиреннән,
Каҗмактыдан чыккан бабасы.

Барда белән Арча арасы...
Җанга рәхәт йомшак һавасы,
Арча киче, Барда таңнары
Күңелләргә кереп каласы.

Барда белән Арча арасы
Дуслык юлы булып каласы,
Каршы алыр, озата барыр әле
Дусларымның җылы карашы.

## СЫНАР ӨЧЕН ЯРАТКАНДЫР...

Татар... Башкорт...
Ут күршеләр.
Ничә гасыр шулай.
Тамырларда кемнәр каны?
Болгар... Кыпчак... Нугай...

Тылмачсыз да
Бер-беребезне
Тиз аңлыйбыз болай.
Бер үк төсле моңландыра
Тальян яки курай.

Белсеннәр дип
Дуслык кадерен,
Сынар өчен шулай,
Төрле милләт итеп безне
Яраткандыр Ходай.

## БАРДА ЯГЫ

Барда ягы — безнең кече Ватан,
Ата-бабам нәселе торган җир.
Унбер Әхмәт, җиде Газизләрең
Оран салган, тәгъбир әйткән җир.

Кушымта:

Яшә, күкрә, гүзәл туган җирем,
Тол буйлары, Барда төбәге!
Иген иккән, матур гомер иткән
Халыкларның дуслык үзәге.

Барда ягы — тук башаклы кырлар,
Кара алтын чыгып яткан җир.
Урман, таулар, күлләр, киң болыннар
Халкым җырларына күчкән җир.

Кушымта.

Барда ягы — олы шәхесләрне,
Зыялы затларны биргән җир.
Шәрифҗандай батыр егетләре,
Сылу туташлары булган җир.

Кушымта.

Барда ягы — сибелгән милләтнең
Телен, рухын саклап калган җир.
Гореф-гадәт, җыен-сабантуйлар,
Милли моңнарыбыз яшәр җир.

## ҮКЕНМИМ

Исбат итә миңа берәү:
«Яши, — дип, — авылда кем?
Укымаган, эш сөймәгән
Һәм эчеп йөргән мескен.

Бөтен талантлы кешеләр
Күптән шәһәрдә инде.

Казынмагыз шушы җирдә
Һәр Ходай бирмеш көнне».

Әйе, зур эш кырыр булсаң
Шәһәр кулай җирдер дә...
Яшәү тамыры — галиҗәнап
Икмәк үсми ул җирдә.

Ил яшәр, авыл яшәсә
(Һәм шул исәптән шәһәр).
Аз гына «югарыдан» да
Ярдәм итсәләр әгәр.
Авыл малае булганга
Үкенмим бер генә дә,
Читкә киткәннәр дә әнә:
«Аулым», — дип өзгәләнә.

## ТУГАН ҖИР

Җиләкле аланнар,
Чәчәкле болыннар —
Балачакның яшел бишеге.
Кайларда йөрсәк тә,
Ни гамәл кылсак та,
Тартып тора үзенә кешене.

Урманы, кырлары,
Ямьле су буйлары —
Табигать бүләге — хәзинә.
Барыннан да бигрәк
Сакларга да кирәк
Шушы гүзәллекне әз генә.

Авылым таулары,
Былбыллы таңнары —
Күңелләргә күчкән җыр икән.
Әнкәң кабере торган,
Кеше кадере булган
Иң изге җир туган җир икән.

## БАШ САУ БУЛСА

Еракларда гомер итүләр бар,
Туган җирне сагынып яшәү бар.
Кайтып күрешергә сәбәпләре —
Әнкәйләр бар, сабантуйлар бар.

Әнкәйләрнең күңеле рәнҗемәсен —
Туган якка ешрак кайтасы бар.
Исән чакта утырып сөйләшәсе,
Хәер-фатихалар аласы бар.

Баш сау булса, сабан туйларына
Булыр әле сагынып кайтасылар.
Кайтмый булмас, авыл картларының
Акыл-киңәшләрен аласы бар.

Әнкәй сөте белән салынгандыр
Туган җирне сөю, яратулар.
Шуңа, ахры, җаннарыма якын

Кайту, каршы алу, озатулар.

**АВЫЛ ҖИРЕ**

Кайда йөрмим, ни гамәлләр кылмыйм,
Авыл малае мин, авылдан.
Алтын таулар вәгъдә итсәләр дә,
Шәһәр чире белән авырмам.

Кечкенәдән минем канга сеңгән
Арыш исе, туган җир исе.
Кырга чыксам, шуңа һәр үләнен
Килә кулга алып иснисе.

Тауларына менсәм, көчем арта,
Чишмәләрнең тоям шифасын.
Бездә генәдер ул шау чыршылар,
Каеннарның төзе, зифасы.

Шартламасы, җиләк, өмеҗесе
Мөлдерәмә тулы бал гына.
Әсир итәр сине һәр почмагы,
Күңел биреп бер күз сал гына.

Бөтен нәрсә гади, үзгә монда,
Табигатькә якын хислерәк.
Авыл җирләрендә яшәүчеләр
Мең тапкыр бәхетлерәк.

**ТУГАН ЯК**

Кайтып киләм
Авылыма
Таныш юлдан.
Күз камаша
Ишелеп-ишелеп
Яуган кардан.
Тирә-ягым
Кар диңгезе,
Йомшак юрган.
Салкынлыгын
Тоймыйм һич тә
Җылы нурдан.

Тәүге тапкыр
Биредә мин
Аваз салган.
Әкияти
Малай чакның
Эзе калган.

Бу кырларда
Әтиләрем
Чәчкән-урган,
Ә үзләре
Бер кашык он
Белән калган.

Башкарылса да
Бөтен эш

Бары кулдан,
Җир кешесе
Бөтенесен
Туендырган.

Кайгылар да,
Шатлыклар да
Уртак булган.
Нурлы, җылы
Туган туфрак
Сыендырган.

Кайтып килəм.
Җиңел, рəхəт,
Күңел тулган.
И туган як,
Шулкадəрле
Сагындырган.

**ҖӘЙГЕ АВЫЛ**

И авыл, син мең шəһəрдəн
мең кабат ямьле вə хуш.
*С.Рəмиев*

Җаннарыма якын бу якларның
Кормалае, Нəби таулары,
Печəннəрен чапкан болыннары,
Шомыртлары, юкə, таллары.

Урманнары тулы кура җилəк,
Тауларында пешə җир җилəк.
Урамыннан аккан чишмəлəрнең
Җидесенə җиде җыр кирəк.

Арышлары, бодай басулары
Күңелемə тирəн уелган.
Кай тарафка гына китсəм дə мин,
Һич чыкмаслар кебек уемнан.

**ПОЕЗД ЧАБА ТУГАН ЯККА**

Поезд чаба туган якка,
Алда авылым үрлəре.
Көтə торгандыр туганнар.
Ничек икəн хəллəре?

Кушымта:

Чит җирлəрдə сагышланып,
Сагынып үтə гомер.
Туган җирне, туганнарны
Бер күрүе — бер гомер.

Поезд чаба... Чəчтəн сыйпап
Исə йомшак җиллəре.
Җиллəре дə җанга якын
Туган-үскəн җирлəрнең.

Кушымта.

Поезд чаба... Кырлар буйлап

Тузанлы юл сузылган.
Тузан бөртеге — гомерләр —
Читтә йөреп узылган.

Кушымта.

**КИТҮ... КАЙТУ...**

***Киткәннәр бар.***

Авылыннан качып киткәннәр бар,
Авырлыктан куркып, эшеннән.
Йортын-җирен сатып киткәннәр бар,
Бәхет эзләп дөнья читеннән.

Бер сүз өчен алынып киткәннәр бар,
Гаепсезгә Себер киткәннәр.
Авыл белән зурлап озатылган,
Ил чакыргач чыгып киткәннәр.

***Кайтканнар бар.***

Тормыш авырлашкач кайтканнар бар,
Ямь тапмыйча шәһәр җиреннән.
Качак булып, куылып кайтканнар бар
Җылы куышыннан, иленнән.

Цинк табутларда кайта кемдер —
Унсигездә китеп барганнар.
«Хәтер китабы»нда кайта бүген
Яу кырында ятып калганнар.

Туган якларына кайта кеше:
Сагынганнар кайта, көткәннәр.
Адашканнар кайта, ялгышканнар,
Кайтмаска дип чыгып киткәннәр.

Кайту-китү, китү-кайтуларда
Кеше гомере, еллар агышы.
Берәүләргә шатлык булып кайта,
Кемнәргәдер — кайгы-сагышы.

**ТУГЫЗ БАЛА ҮСТЕК**

Тугыз бала үстек — зур гаилә.
Тугызыбыз тугыз төрле без.
Тугызыбыз тугыз җиргә чәчелеп,
Үзебезчә эшләп йөрибез.

Тугыз холык, тугыз характер без,
Үссәк тә бер ата-анада.
Шундый чакта әйтәләрдер: «Аттан
Туа, — дип, — ала да, кола да».

Кемдер сабыр, кемдер артык кырыс,
Кемдер йөри янып, кем көлеп.
Миңа калса, яши бик күбебез
Үз бәхетен, кадерен белеп.

Һәммәбезнең үз һөнәре, эше,
Һәркем үз урынында бик кирәк,

Дөнья мәшәкатен сәбәп итеп,
Хәлләр белешәбез бик сирәк.

Ярый әле елга бер булса да
Очрашабыз туган якларда.
Әти-әни кабере, сабантуйлар
Кайтмас җирдән тартып кайтара.

**КАЙТАМ ӘЛЕ**

Кайтам әле туган авылыма.
Монда минем тәүге эзләрем.
Туганнарның, күрше-күләннәрнең
Күреп килим нурлы йөзләрен.

Кайтам әле, авыл картларының
Ишетим әле киңәш сүзләрен.
Иртә киткән әткәй-әнкәйләрнең
Күргән төсле булыйм үзләрен.

Кайтам әле, яшьлек кенә бары
Ничек узган, кайчан? Сизмәдем.
Миләш-баланнарда кызыл тәлгәш.
Көтеп тора инде көзләрем.

Язмыш җиле кая ташласа да,
Кайтырмын мин барыбер, түзмәмен,
Кендек каным тамган туган җирне
Сагынып яшәүләрдән бизмәмен.

**САБАН ТУЕ БҮГЕН**

Өмет уятучы кырларыңа
Горурланып бер күз ташла да
Төш болынга, елга буйларына.
Сабан туе бүген, тантана.

Сабан туе — олы хезмәт туе —
Басу түрләреннән башлана.
Мәйданнарда иң беренче булып
Игенче намусы яклана.

Сабан туе — күркәм, гадел бәйрәм,
Хәләл көчең белән аклана.
Хәрәмләшү, алдашу юк монда,
Ясалмый беркемгә ташлама.

Кимсетелми җиңелде дип кем дә,
Соңлап килгән ат та мактала.
Буыннардан күчә-күчә шушы
Изге гореф-гадәт саклана.

Иген иккән, матур бәйрәм иткән
Халкым исән, күңел шатлана.
Бабаларым мирас иткән җирдә
Сабан туе бүген, тантана!

**МӘХӘББӘТ ЧИШМӘСЕ**

*Татарстанның Әгерҗе районы Яңа-Акхуҗа авылы яшьләренә багышлана*

Кечкенәдән гашыйк идем
Мәхәббәт чишмәсенә.
Ышанмадым, үсеп җиткәч,
Читләргә китәсемә.

«Мәхәббәт чишмәсе» диеп
Кем куйган исемнәрен?
Үзем беләм: ерак киткәч,
Ни уйлар кичергәнем.

Мәхәббәт чишмәсе — саф су,
Мин генә микән эчкән?
Туган авылым, һичкайчан
Шул чишмәң чыкмый истән!

**МАРТ**

Күк йөзе нинди зәп-зәңгәр,
Һавалар нинди аяз!
Март ае бүген урамда,
Тәрәзәгә чиртә яз.

Котырса да бураннары,
Салкыннар инде юаш.
Җылылык сибеп дөньяга,
Елмая күктән кояш.

Өй артында тамчы тама:
Көне буе тып та тып.
Табигатьнең бу мизгелен
Мөмкинме соң туктату?

Уяна җирдә тереклек,
Күңелләргә тула наз.
Туган якның язларына
Күпме соклансаң да аз.

**КЫЧЫТКАННАР**

«Нигез елый» диючеләр хаклы.
Елый икән нигез тавышсыз...

*Ш.Маннапов*

Кешеләре киткән, авыл беткән.
Урыны гына ята каралып.
Кычытканнар тора еламсырап,
Нигез ташларына сарылып.

Кычытканнар исән, ни хәлдә дә
Нигезләрен ташлап китмәгән.
Үз кадерен белеп яшәгәнне
Туган туфрак ятим итмәгән.

Туган җиргә тугры кычытканнар
Азмы бала чакта елаткан.
Кычытканга чагылып үткән еллар
Бәхетлерәк булган күп яктан.

Кычытканнар! Әрсез кычытканнар!
Шифалы да, усал, хәтәр дә.
Беткән авыл рухын саклап торган
Кычытканнар чыкмый хәтердән.

**КАЙТСАМ ТУГАН ЯККА**

*(Җыр)*

Кайтсам туган якка
Бозлар аккан чакта,
Агышларын карап калырмын.
Басу-кырларыннан,
Тургай җырларыннан
Күңелемә моңнар алырмын.

Кайтсам туган якка
Болын чәчкә чакта,
Үлән исе җанны иркәләр.
Җәйнең бизәкләре —
Каен җиләкләре,
Өзеп алмый үтсәм, үпкәләр.

Кайтсам туган якка
Көзләр кергән чакта,
Кайтмый калган дуслар көнләшер.
«Безне якын күреп
Кайттыңмыни?» — диеп,
Миләш-баланнарым эндәшер.

Кайтсам туган якка
Карлар яуган чакта,
Бураннары урап алырлар.
Шушы аклыклары
Кайтмас вакытларның
Гомерем буе истә калырлар.

Кайтсам туган якка
Бик сагынган чакта,
Күрешүләр була кадерле:
Ямьле туган җирләр,
Искә алмый кемнәр —
Кеше күңелләре хәтерле.

**КАРЛАР ЯВА**

Карлар ява. Кышның да бит
Үз бизәге, үз ямьнәре.
Карлар түгел, сүтелгәндер
Әниемнең каз мендәре.

Карлар ява. Күчә җиргә
Аклыклары, сафлыклары.
Күмелеп кала карлар белән
Тормышымның ваклыклары.

Ак төсләрдән, пакь хисләрдән
Җылынып китә дөньям тагын.
Карлар ява, сагындырып
Ерак калган малай чагым.

**АВЫЛЫМ ТАУЛАРЫ**

Таулы якта туып үскәнгәме,
Кечкенәдән тауга гашыйк мин.
Кайткан саен илһам, көч алырга
Иң беренче шунда ашыктым.

Малай чакның рәхәт минутларын
Таулар белән ешрак бәйләдем.
Кышларында чаңгы, чана шудым,
Җиләкләрен җыйдым җәйләрен.

Хәтеремдә яшьләр менгән чаклар
Шау-гөр килеп кичке уенга.
Әти сөйли: «Элек бу тауларда
Үтә иде сабан туе да».

Үткәннәрнең телсез шаһитлары —
Табыла монда окоп эзләре.
Күргән төсле булам шул чагында
Бабамнарның нурлы йөзләрен.

Монда алар гомер кичергәннәр,
Тормышлары булган кыеннан.
Бәхет эзләп читтә йөргәне дә
Ахыр монда килеп сыенган.

Менгән саен һаман биеккәрәк,
Сафлана җан, арта хозурлык.
Тауга карап таулар булмасак та,
Без шулардан алдык горурлык.

Кечкенәдән канга сеңеп калган
Авылым тауларына тугрылык.
Шушы хисләр бүген чишмә төсле
Йөрәгемнән чыга ургылып.

**АШЫГАБЫЗ**

Кая шулай ашыгабыз икән?
Җирдә яшәп калу өченме?
Киләчәккә корган уй-хыяллар
Тизрәк чынга ашсын өченме?

Ашыгабыз,
Малай чакта зур булырга,
Егет булгач — көрәшергә, дан алырга,
Ир булгачтын — бил бирмәскә, җиңелмәскә,
Бабай булгач — бирешмәскә, чигенмәскә.

Ашыгабыз,
Картайгач та ашыгабыз.
Үтте гомерем язлары дип уфтанырга,
Эчтән генә сызланырга, уйланырга,
Яшь чакларны искә төшереп моңланырга.

Ашыгабыз, кая ашыгабыз?
Безне әллә дөнья куалый.
Дөнья түгел, бу дөньяны шулай
Куалаган ул — без хыялый.

Ашыктырып гомер агышларын
Керә яңа фасыл.
Җәйләр белән көзләр алмашына.
Гасыр белән гасыр.

Көз сарысы иңгән яфракларым
Тиздән җиргә ятыр.
Алар язмышы да безнең сыман,
Туган туфрак тартыр.

Күңел генә ямьле җәйләренә
Кабат-кабат кайтыр.
Әле дә дусларым бар, көзләр моңын,
Сагышны таратыр.

## КӨЗГЕ МОҢ

Өзелде дә кинәт сары яфрак
Иңнәремә килеп сарылды.
Шушы мизгел, сары сагыш булып,
Күңел кылларыма кагылды.

Көзге җилдә бөтерелә яфрак,
Оча, югарыга тартыла.
Үзе сизми: гомер язы үткән,
Яшимен дип һаман талпына.

Кире кайтыр иде, булдыра алса,
Яшел яфрак булган чагына.
...Кешеләр дә шулай, торган саен
Яшьлекләрен күбрәк сагына.

## РӘССАМ БҮЛӘГЕ

Пейзаж бүләк итте күршем.
Уйга калдым бер мәлгә.
Тере табигать каршыма
Килеп бастымы әллә?..

Елга агышлары салмак,
Каеннар моңсу хәлдә.
Ник сары төсне күп биргән,
Рәссам ялгышкан мәллә?

Күршемнең бу иҗат эшен
Мин яхшыга юрадым.
Мөгаен, бу август ахыры,
Көз башы, дип уйладым.

Аңларга була анысы
Мондый хәлне ничек тә.
Рәссамның яше бүген дә
50 түгел, 70тә.

## КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ

*(Җыр)*

Көзләр кергәндә, каршы аласың,
Кояшлы язда озатып каласың.
Дәрескә чакырып адәм баласын

Көненә ничә чыңлап аласың.

Кушымта:
Кыңгырау, көмеш кыңгырау!
Кыңгырау! Тәүге яңгырау.

Үзең кечкенә, тавышың көчле.
Көч алып синнән, алабыз «бишле».
Укысак начар йә алсак «өчле»,
Ачулы, усал чыңлыйсың төсле.

Кушымта:
Кыңгырау, көмеш кыңгырау!
Кыңгырау! Серле яңгырау.

Мәктәп еллары ничек тиз үтә.
Аерылыр вакыт килә дә җитә.
Кыңгырау чыңлап озатып калган чак, —
Шунысы бигрәк бәгырьне өтә.

Кушымта:
Кыңгырау, көмеш кыңгырау!
Кыңгырау! Соңгы яңгырау.

Елап туа кеше. Сөенәбез,
Елаганын күреп.
«Бәхетең белән кил әйдә», — дип,
Мактауларга күмеп.

Еламыйча китә кеше,
Озатабыз елап.
Искә алып гомер юлын,
Яхшылыгын уйлап.

Туу, үлү — яшәешнең
Бары ике чиге.
Килә, китә, онытыла.
Яши игелеге.

**ТАНЫШ ХӘЛ**

Җәй уртасы. Таныш болын.
Кигәвеннәр бирми тынгы.
Печән чабам киерелеп,
Уйный кулда чыңлы чалгы.

Покосларым ята тигез.
Коелып кала җир җиләкләр.
«Тимә, — диеп, — чәчәкләргә», —
Бөтерелә күбәләкләр.

Җиләк... Чәчәк... Күбәләкләр...
Таныш миңа алар хәле.
Җәй кебек кыска гомернең
Көзләренә күчкән мәле.

Узып бара тагын бер ел.

Үтәбез гасыр чиген.
Күңелнең якты уйларга
Күмелгән чагы бүген.

Белсәк тә гомер дигәннең
Мәңгелек түгеллеген.
Барыбер төпкә җигелеп
Тартабыз тормыш йөген.

Җир кешесе булып тугач,
Бурычлы без, хаклы без.
Өмет-ышанычлар төяп,
Яңа чорга атлыйбыз.

Кеше гомере бары мизгел —
Бер күз ачып йомган ара.
Өлгермисең әйләнергә,
Бүгенгебез ерак кала.

Берәүләре әле яңа
Язларына юллар яра.
Саубуллашып көзләр белән
Кемдер инде китеп бара.

Җир кануны: киткәннәрдән
Эшләр кала, җырлар кала.
Яңа җырлар... Яңа буын
Оныкларга шәһәр сала.

**ӘЙЛӘНӘМ ДӘ КАЙТАМ ҮТКӘННӘРГӘ**

*(Җыр)*

Әйләнәм дә кайтам, җыр ишетсәм,
Әткәйләргә, иске көйләргә.
Әткәй дә юк бүген, тальяны да...
Калды бары сагынып сөйләргә.

Укымаган, хәреф танымаган
(Кемнәр белсен, нәрсә уйлаган).
Көне буе кырда сука сөргән,
Ә кичләрен гармун уйнаган.

Назламаган тормыш, бәхетен аның
Сугыш, авырлыклар урлаган.
Шуңа, ахры, бик еш моң-зарларын
Тальянына кушып җырлаган.

Әйләнәм дә кайтам, җыр ишетсәм,
Үткәннәргә, бала чагыма.
Күңел шулчак әткәй төсе сеңгән
Иске тальяннарны сагына.

Уфтанмыйк та, зарланмыйк та,
Безнең, дип, гомер үтә.
Чәчәкле җәйләр озатса,
Җимешле көзләр көтә!

Тормыш — кросс,
Тормыш кырыс.
Тормыш — кросс,
Йөгерәбез
Сабантуй аты кебек.
Беләбез: алдан килгәнне
Бәхет каршылар көлеп.

Тормыш кырыс.
Бөтенесен
Йөрәк белән түләсе.
Тик финишына гомернең
Килә соңлап киләсе.

**МОҢСУ ХАЛӘТ**

Көзге алан. Сөенеп куйдым
Ак ромашкалар күреп.
Ә барыбер шушы халәт
Күңелне алды телеп.
Табигатьтә бераз моңсу,
Төсләргә бай чак икән.
Гомер-җәйдән соң яз түгел,
Көзгә күчү хак икән.

Гасыр алмашына,
Еллар ага,
Тик без түгел.
Китә алмый
Ямьле җәйләреннән
Ярсу күңел.

Үтеп бара Елан елы,
Ат елына керәбез.
Төпкә җигелеп тартасылар
Алда әле. Беләбез.

Нәкъ Тукайча: без тынычта
Аттан артык эшлибез.
Кече яшьтән ат ялына
Ябышып үскән кеше без.

Шуңа бераз атка охшаш
Сабыр, тыйнак холкыбыз.
Эшләп кенә татарлыгын
Саклап калган халкыбыз.

Булса булсын ат хезмәте,
Бирмәсен эт язмышын.
Эшләп тә тибелеп яшәгән
Кадерсезләр азмы соң?

Рәхим ит, әйдә, түрдән уз,
Ат елы, уңыш елы.
Һәр туар таңнар өметле,
Бәхетебез булсын тулы.

Гомер — йомгак. Малай чакта
Килә тиз сүтәсе.

Һәм тәгәри киткән эздән
Чыгып йөгерәсе.

Гомер — йомгак. Олыгайгач
Килми югалтасы.
Сүтелмәслек итеп үзен
Килә чуалтасы.

**ИҢ БӘХЕТЛЕ ЧАК ИКӘН**

55 яшь! Хыял-хискә
Күңел сизгер, сак икән.
Гомер алда, тик барыбер
Уйландырыр чак икән.

55 яшь кем өчен дә
Шунысы кыен як икән:
«Үтте гомер җәйләрем», — дип
Сөйләнүләр хак икән.

55 яшь оныклар дип
Яши башлар чак икән.
Тәҗрибәле, дәрәҗәле...
Иң бәхетле чак икән.

**САУБУЛЛАШУ**

*(Җыр)*

Ничек бик тиз үтеп китте икән
Бала чаклар, мәктәп еллары?
Кай тарафка безне алып китәр
Сикәлтәле тормыш юллары?

Кушымта:

Сау бул инде, мәктәп, без китәбез.
Еллар аша кайтырбыз очып.
Безгә белем биргән апаларны,
Абыйларны алырбыз кочып.

Кошчыкларын очыра бүген мәктәп,
Хыял канатлары иңнәрдә.
Алда күпме авыр сынауларны
Туры килер безгә җиңәргә.

Кушымта.

Сагындырып искә төшәр әле
Укып йөргән күңелле чаклар.
Классташлар белән соңгы тапкыр
Тол буенда яккан учаклар.

Кушымта.

**ТУГАН КӨН**

*(Җыр)*

Бәйрәмнәрнең иң күркәме,
Иң якыны — туган көн.
Мондый истәлекле көнне
Искә алмый икән кем?!

Кушымта:

Туган көн елга бер генә.
Кил, ял итеп кит әле.
Без болай да бу дөньяда
Кунак кына бит әле.

Өстәлләргә тәмле ашлар,
Өчпочмак, чәкчәк менсен.
Сезнең шатлыкка ямь өстәп,
Тәрәзәдән кояш көлсен.

Кушымта.

Туган көн — гаилә бәйрәме.
Бәхетле булсын һәркем.
Җылы-җырлы өегезгә
Мәхәббәт нуры иңсен.

Кушымта.

Туган көн белән котларга
Дус, туган, күрше керсен.
Ходай сезгә сәламәтлек
Һәм озын гомер бирсен.

Кушымта.

**ТУЙ КҮЛМӘГЕ**

*(Җыр)*

Алтын балдак һәм ак күлмәк —
Яшьлек туе бизәге.
Туйлар ясый, гаилә кора
Яшь парларның зирәге.

Кушымта:

Бер-берсен табышкан,
Яратып кавышкан
Пар аккошлар кебек икегез.
Бер-берегезне назлап,
Ярты сүздән аңлап,
Гомер юлын матур үтегез.

Алтын балдак, туй күлмәге
Бик килешә үзеңә.
Икегез дә пар килгәнсез,
Тимәсен лә күз генә.

Кушымта.

Гомер буе бер-берегезне
Язсын назлап сөяргә.
Туры килсен туй күлмәген
Тик бер генә кияргә.

Кушымта.

Ак күлмәкне — туй күлмәген
Кер кундырмый саклагыз.
Тормыш — кырыс, авырлыкны
Җиңеп, бергә атлагыз.

Кушымта.

Шаярып кына да кайчак
Ятларга күз атмагыз.
Безнең изге теләкләрне,
Ышанычны аклагыз.

Кушымта.

**ИСКӘ АЛАМ**

Яшьлектәге сүнмәс хатирәләр
Алып килә бик еш Казанга.
Рәхмәтлемен мәңге язмышыма
Биш ел гомерем шунда узганга.

Бүгенгенең кыен минутлары
Тынгылык бирмәсә бу җанга,
Студент чакларны искә алам,
Сәфәр кылам нурлы Казанга.

Уйлар гына микән... Тормыш үзе
Искә төшерттерә һаман да, —
Минем йөргән сукмакларга басып
Кызым укып йөри Казанда.

**ӘНИ КИРӘК**

Иң беренче
Әни кирәк.
Юктыр җирдә
Әниләрдән
Кадерлерәк.

Егылсак та,
Еласак та
Әни кирәк.
Шатлыкта да,
Кайгыда да
Безгә терәк.

Әни назы,
Әни сүзе
Сеңсә күбрәк,
Абынулар,
Ялгышулар
Була сирәк.

Мактаса да,
Тиргәсә дә
Әни кирәк.
Әни кеше
Иң акыллы
Һәм иң зирәк.

Олыга да,
Кечегә дә
Әни кирәк.
Әни булса,
Яшәүләре
Җиңелерәк.

Исән чакта
Кадерләрен
Белик күбрәк.
Игелекле,
Иң изге зат
Әни кирәк,
Әни кирәк.

**ЯХШЫ КЕШЕЛӘР ЕШРАК КАГЫЛА**

Сүнеп барган чакта ышанычлар,
Авырлашса тормыш тагын да,
Ярдәмләшер, терәк булыр дуслар,
Яхшы кешеләр, шөкер, табыла.

Җиңел түгел яхшы булулары —
Андый җаннар ешрак кагыла.
Ак төсләргә җирдә, пакь хисләргә
Каралыклар тизрәк ягыла.

Начарлыкка күнекмәгәнгәме,
Кеше күбрәк акка табына.
Тышта — кояшлы яз, ә күңелең
Ак буранлы кышны сагына.

**БЕЗ БУ ҖИРНЕҢ ӘРСЕЗ КУНАКЛАРЫ**

*(Җыр)*

Керде алтын көзләр,
Шиңде яфрак-гөлләр,
Үтеп үзәкләргә җил исә.
Әллә инде без дә
Гомер көзебезгә
Кереп барабызмы югыйсә?

Кушымта:
Килү, яшәү, китү —
Кабыну, яну, сүнү.
Әйтерсең лә утлы күмерләр.
Без бу җирнең бары
Әрсез кунаклары.
Һай кыска шул, кыска гомерләр.

Бушап калды кырлар,
Тиздән төшәр карлар.
Җанга сагыш өргән көз үтәр.
Абынмый ялгыштан,
Зарланмый язмыштан
Гомер итүләргә ни җитәр?!

Кушымта.

Кыш артыннан язлар,
Аннан җәйге назлар
Бер-бер артлы тезелеп үтәләр.
Кешеләр дә шулай,
Аккан дәрья судай
Киләләр дә җиргә... китәләр.

Кушымта.

**ШУНДЫЙ ТӘРТИП**

Монда шундый тәртип:
акылы барның
Балта белән башын
чабалар...
*М.Җәлил*

Бездә шундый тәртип: югарыда
Утыручы Илбаш агалар
Көнаралаш закон чыгаралар,
Указ арты указ язалар.

Менә берсе — безгә кагылганы —
Җирле реформалар буласы.
Авыл түгел, поселение булып
Кирәк булыр яшәп каласы.

Сельсоветлар түгел — үзидарә.
(Бу этапны узган идек бер.)
Киңәш итү дә юк, аңлашу да,
Халык өчен, имеш, барыбер.

Үзәк күчкәч, мәктәп, ясле беткәч,
Яшьләр китәр, нигез таралыр,
Киткәннәрдән бары ядкәр булып
Зыярат калыр, хәтер, моң калыр.

Вәриз, Толач, Кордак, Күчтәнти баш...
Тагын күпме бетеп калырбыз?!
Еллар үткәч, беткән авылларда
Сабантуйлар ясап алырбыз.

Бездә шундый тәртип. Нәтиҗәсен
Уйлап бетермәүдә хатабыз.
Чит үрнәкләр күреп кайтабыз да
Үзебезчә җимереп ятабыз.

## САБЫЙ КАЙТТЫ ӨЙГӘ

Февраль кары ява,
Якаларга тулып.
Сабый кайтты өйгә,
Уртак шатлык булып.

Ята түшәгендә,
Әнисенә сыенып.
Тәрәзәдән төшкән
Кышкы нурга коенып.

Артты мәшәкатьләр,
Ял итүне оныт.
Тормышка ямь өстәп
Онык кайтты, онык.

## ОЛУГ ШАГЫЙРЬЛӘРНЕ УКЫЙМ

Мусаны укыйм... Җырлары
Күңелне ала телеп.
Уфтанып куям... нигә мин
Язалмыйм аның кебек?!

Фәнисне укыйм... Көчле рух.
Кайдан килә бу халәт?
Йа Ходай, дим, ник бирмәдең
Миңа да шундый сәләт?!

Туфанны укыйм, Сибгатне...
Көч алам, илһам алам.
Яктыра күңел офыгым,
Сафлана сулар һавам.

Тукай шигырьләрен укыйм...
Җаныма моң сарыла.
Халкым диеп янган затлар
Йөз елга бер табыла.

Олуг шагыйрьләрне укыйм,
Мең янам, мең көенәм.
Ә барыбер үзем булып
Калганыма сөенәм.

Сельсовет түгел, авыллар
Поселение күптән.
Димәк, инде үзебезчә
Яши башлыйбыз икән.

Поселение... Подселение...
Германия үрнәге.
Башлык булып сайландылар
Иң шәпләре, зирәге.

Реформа арты реформа
Гел дә Рәсәйчә икән.
Тик кара сакал кайда да
Артыңнан калмый икән.

Исемдә түгел, җисемдә.
Шуны аңлый алмыйбыз.
Авылны үзгәртәбез, дип,
Буш сүз сөйләп алдыйбыз.

**ӘФГАНСТАН — ЙӨРӘК ЯРАМ**

Үз улларын зур сугышка
Алып керде Рәсәй Ватан.
Озакламый каршы алды
Кайнар җилле Әфганстан.

Таулар иле – Әфганстан,
Һәр җирендә мәхшәр купкан.
Таулары да безгә каршы —
Яшеренеп ата «дошман».

Кирәксезгә күпме күз-яшь,
Күпме безнең түгелде кан.
Югалтуларның иң зуры —
Ятып калды 15 мең җан.

Табутта кайтты күпмесе,
Яздырып ананы һуштан.
Кем гаепле? Балаларга
Утка керергә кем кушкан?

Туры килде безнең чорга,

Кемгә — табут, кемгәдер — дан.
Йөрәк ярам булып калды
Кайнар җилле Әфганстан.

## ЧИР КИТӘ, ГАДӘТ КИТМИ

Әйтеп куйды беркөн кызым
(Гаҗәпләндем сүзенә):
«Шулкадәрле юләр булып
Яшәгәнсез сез генә?!

Көн иткәнсез, риза булып
Тапканына, барына.
Нигә шунда башкалар күк
Җайлашмаска аз гына?!

Йортың иске, юк машинаң,
Юк байлыгың, юк даның.
Кешене күр! Ничек яши,
Сутын имеп дөньяның...»

Мондый сорауны ишетеп,
Кемнең соң эче пошмый?
Әйтә алмадым кызыма:
«Миңа, — дип, — намус кушмый».

Үзем дә беләм кирәген,
Чор башка, тәртип башка.
Кешегә иярәм диеп,
Орыйммы башны ташка?

Өйрәттеләр: «Тәртипле бул,
Урлашма, чапма алдан!»
Ахрысы, шушы тәрбия
Каныма сеңеп калган.

Җайлашып булмый заманга,
Аңлыйм да кебек юкса.
«Чир китә, гадәт китми», — дип
Әйтмиләр, ахры, юкка.

## ЙӨРӘКНЕ УЙЛАР ТАЛЫЙ

Җәйге авыл. Урам тып-тын.
Бу хәл соң кемгә ярый?
Шау-гөр киләсе балалар,
Чабып йөрисе малайлар
Өйдә боевик карый.

Чәчелмичә калган кырлар
Елыйлар кебек зарый.
Сыер савасы апалар,
Иген игәсе агайлар
Ачы язмышын каргый.

Һәр йорт аша ялгыз карчык,
Күзләре моңсу карый.
Таза-сау чагын сагынып,
Бары Ходайга табынып,
Калган гомерен саный.

Җәйге авыл. Урам тып-тын.

Чәчләрне җилләр тарый.
Җилләр түгел, шушы халәт,
Авыл кешеләрен җәлләп,
Йөрәкне уйлар талый.

**ӘМАНӘТ**

Кеше хакын хаклау, вөҗдан, намус —
Өлкәннәрдән күчкән әманәт.
Ахры, шуңа кыен чакларда да
Чыгармадык кебек яман ат.

Рәнҗетмәдек авыр сүзләр әйтеп,
Кеше өлешенә кермәдек.
Кемнәргәдер ярап, койрык болгап,
Тәлинкәләр тотып йөрмәдек.

Кызыкмадык малга, дәрәҗәгә.
Булмады һич андый хирыслык.
Тик хезмәттә таптык чын бәхетне,
Кыйблабыз булды дөреслек.

Беләм: күпләр безне аңламады.
Санадылар хәтта җүләргә.
Санасыннар! Кеше булып үстек,
Кеше булып язсын үләргә.

Иманнар сау, рухыбыз нык калыр
Купканда да җирдә кыямәт.
Үзгәрү яшеннән уздык бугай,
Әманәткә булмас хыянәт.

**ИСКӘ ТӨШӘ ӘНКӘЙ СҮЗЛӘРЕ**

Әйтә торган идең: «Өлкәннәргә
Авыр сүз әйтмәгез, балалар!»
Шул сүзләрең, әнкәй, бүгенгедәй
Җанга кагылып-кагылып алалар.

Әйе, киңәшеңне тотмаганбыз.
Калдырганбыз картлар хәтерен.
Гаепләп йә ватып кичәгене,
Җайлап әйталмыйча әйтерен.

Намус беткән, әхлак зәгыйфьләнгән,
Имансызлар арткан заманда,
«Кем гаепле?» дигән кискен сорау
Борчып тора шуңа һаман да.

Нинди булыр бездән соңгы буын,
Аңлармы кеше кадерен?
Тәрбияләп, соңгы юлга озатып
Зиярәт кылырлармы каберен?

«Өлкәннәрне берүк рәнҗетмәгез!»
Искә төшә әнкәй сүзләре.
Шушы сүзне әйткән әнкәйләрнең
Кадерләдек микән үзләрен?

Гомер кыска. Китә тора
Ил карты — ветераннар.
Тарих битләренә күчкән
Алар көрәшкән таңнар.

Гомер кыска. Китә тора
Яшь кенә егет-җаннар.
Чечня җирендә ни өчен
Кан койганын кем аңлар?!

Гомер кыска. Бер сәбәпсез
Түгелмәс иде каннар,
Ут эчендә корал тотып
Сугышса түрә-җаннар.

Бер мичкә балны бозарга
Бер кашык дегет җитә.
Ялгыш әйткән бер кыек сүз
Кеше күңелен өтә.

Көл итү өчен җиһанны
Бары минутлар җитә.
Гөлгә күмәргә бу җирне
Күпме вакытлар китә?

Ирек даулаган төбәкләр
Бер акыллы сүз көтә.
Юкса монда Илбашының
Бары бер сүзе җитә.

**БАСУ КАПКАСЫ**

Еш кайтыла хәтер буйлап
Үткәнгә — малай чакка.
Килә дә баса күз алга
Авыл башы... Зур капка.

Гади нәрсәләр югыйсә:
Усак киртә, җил капка.
Тотып тора мал-туарны,
Җибәрми басу якка.

Акыллырак булган картлар:
Күңле саф, кулы алтын.
Яшәгәннәр, көрәшкәннәр
Аңлап чын икмәк хакын.

Җаным сыкрый күреп бүген
Тапталган иген кырын.
Сагынып куям авылның
Басу капкалы чорын.

**ТОРМЫШ — ОРМЫШ**

Кәртле уенына охшап
Бара төсле тормыш.

Кичә рәтле кебек иде,
Бүген тормыш — ормыш.

Козырь дип йөргән кәртебез
Гади бер туз икән.
Намус, вөҗдан дип сөйләүләр
Чоры инде үткән.

Уенга кергән һәр адәм
Ота йә оттыра.
Берәүгә җайлы, ә кемдер
Аптырашта тора.

Козырь кемдә, шул хәл итә,
Шунда бөтен хикмәт.
Тормыш — кәртле уен. Кирәк
Ничек гомер итмәк?

Азартка кереп, еш кына
Кителә талашып.
Кеше икәнне онытып,
Якадан алышып.

Явызлыкта, кыргыйлыкта
Ярыша-ярыша һаман,
«Ерак бабалар»га охшап
Барабыздыр сыман.

**ЯЗМЫШЫМДА ЯЛГЫШМАМ**

Өй каршындагы агачны
Кисмим, каен булса да.
Сыгылмамын алар кебек,
Күпме кыен булса да.

«Каен агач — кайгыга» дип,
Начарга юрыйммыни?
«Язмыштан узмыш юк» диләр,
Гел елап торыйммыни?!

Сау икән җаным, иманым,
Язмышымда ялгышмам.
Әнә каеннар саргайсын
Миңа тияр сагыштан.

**КЕШЕ БУЛЫЙК!**

Берәүләр бар: яшьлектә
Яманлыклар кылганнар.
Ә хәзер, дингә бирелеп,
Тәүфыйкка утырганнар.

Шундыйлар бар: гомергә
Бары эш дип янганнар.
Мәчеткә йөрмәсәләр дә,
Кеше булып калганнар.

Иманлы булу яхшы ул,
Изге эш ул — динлелек.

Ләкин бу юлдан киткәнче,
Кеше булыйк иң элек.

**АЗАН МОҢЫ**

Азан тавышы манарада,
Җаным елый моңыннан.
Гореф-гадәтләрем кайта
Изгелеккә корылган.

Иман сатып, вөҗдан сатып
Күпме еллар торылган.
Соң булса да, заман җиле
Яхшы якка борылган.

Яман чирләрдән арыныйк
Бергә-бергә бүгеннән.
Азан моңы, иман нуры
Чыга йөрәк түреннән.

Милләтне милләт итүче
Шулдыр, бел:
Гореф-гадәт, милли кием,
Туган тел.

Ак күлмәкләр киям сирәк,
Белгәнгә керләнәсен.
Күлмәк нәрсә... юдың-кидең,
Күңелең керләнмәсен.

Яхшылык иткән кешегә
Тазалык-саулык телә.
Саулыкның нәрсә икәнен
Чирләп караган белә.

Яхшы адәм бик тиз китә,
Явызлары кала.
Күрәсең, җир андыйларны
Бик теләми ала.

**БӨРКЕТ ҺӘМ ТАВЫК**

Тормыш кырыс. Бөркеткә дә
Туры килә яшәргә.
Кайчагында тавыктан да
Түбәнрәк төшәргә.

Мактанып йөрсә дә тавык
Үзенең кирәклегенә,
Күтәрелә алмый барыбер
Бөркет биеклегенә.

**АЗ ҺӘМ КҮП**

Берәү яши: гомер буе
Акыл туплый, белем җыя.
Кыен чакта бер киңәше

Кешеләргә ярап куя.

Икенчеләр мал җыялар,
Онытыла чама хисе:
Кереп китә шома гына
Башкаларның хәләл көче.

Өченчеләр бер сәбәпсез
Хәмер эчеп акылын җуя.
Гаиләсенең, күршесенең
Бер дә юктан җанын кыя.

Кемдер йөри азып-тузып,
Кемдер — талап, урлап, алдап.
Ә кемнәрдер — тапканының
Очын очка чак-чак ялгап.

...Бик аз кирәк кешеләргә
Хайван булып алу өчен.
Бик күп кирәк бу дөньяда
Кеше булып калу өчен,
Үзең булып калу өчен.

**ЯТИМЛЕКТӘ КЕМ ГАЕПЛЕ?**

Кемнәргәдер туганда ук
Ятим исеме ябышкан.
Ил картлары юатканнар:
«Язмыштан ул, язмыштан».

Кырык бердә дә ятимнәр...
Холык-фигыле кырыстан.
Алар өчен ятимлекләр
Сугыштан, тик сугыштан.

Әйтеп булмый бүгенгене
Сугыштан дип, язмыштан.
Миңа калса, йә әниләр,
Йә әтиләр ялгышкан.

Тудырганнар, калдырганнар
Ятим итеп тумыштан.
Юкса песи дә баласын
Яшәтергә тырышкан.

Яхшы булыр иде дә бит,
Якасыннан алышсаң.
Кызганабыз. «Ат та, — дибез, —
Абынадыр ялгыштан».

...Ялгышканнар арта бара
Безнең мондый караштан.

Эш сөйгәннәр гомер буе
Тырышып эшләп ята:
Иген игә, мал үстерә
Һәм яшелчәсен сата.

Эш сөймәгәннәре исә

Бар булганны тарата.
Башта җирен, аннан өен,
Ахырда үзен сата.

Беренчеләр — нинди горур,
Бәхете, көче арта.
Икенчеләр, ни аяныч,
Ясый төзәлмәс хата.

## БАРЫ БЕР СҮЗ

Бер сүз җитә
Кеше күңелен бозу өчен.
Бер сүз җитә
Гасабига кызу өчен.

Бер сүз җитә
Ялгышларны төзәтергә.
Бер сүз җитә
Язмышларны үзгәртергә.

Ә кайчакта
Күңел өчен бер сүз җитми.
Бары бер сүз...
Йөрәк өчен эзсез үтми.

## ТАРКАЛГАН ХУҖАЛЫКТА

Бер тавыш юк. Шомлы тынлык монда,
Аңлатыплар булмый ничек тә.
Караучысыз калган картлар сыман
Басып калган ферма бер читтә.

Ишекләре ватык, тәрәзәләр,
Түшәм, стеналар таралган.
Җимерек идән, тузган утлыклары...
Үткәннәрдән бары шул калган.

Кем уйлаган аның менә шулай
Мескен хәлгә төшеп каласын.
60 елдан артык бергәлекнең
Күрмәдекме бер дә файдасын?

Кайда калды гөрләп торган чагың,
Көчле, таза чагың кайда соң?
Силос исе, салам исе белән
Күңелемә кереп калгансың.

Кайтып киләм ферма тирәсеннән,
Искә төшә картлар әйткәннәр.
Алар бездән күпкә акыллырак,
Җиде үлчәп, бер кат кискәннәр.

## ШКАФЫМДА ТОРА КОРЪӘН

Яздырыйм, дип хак юлымнан
Иблис мәлгунь кора план.
Саклап мине бу явыздан
Шкафымда тора Коръән.

Коръән тора, яшел тышлы.
Ачып карыйм һәрбер битен.
Танысам да хәрефләрен,
Укып китү әлегә читен.

Читен, чөнки бала чактан
Оныттыргач «бисмилла»ны.
Тукып торгач: — Дин, — дип, — агу, —
Дошман ясап һәр мулланы.

Алласын да, мулласын да
Ташладык та пыр туздырып,
Мактаныштык, күкрәк кактык,
Бер-беребезне уздырып.

Шуның белән нәрсә оттык?
Бетте вөҗдан, качты иман.
Арткан саен имансызлар,
Көн итүләр ай-һай яман.

Арындык та яман чирдән
Алла кушып. Бүген күрәм:
Алдый алмас инде иблис,
Шкафымда тора Коръән.

## ҖИР — АНА

Яратабыз кабатларга:
Җир — Ана.
Шулай булгач, бурычлыдыр
Без аңа.

Тик әлегә җибәрәбез
Без хата.
Үзен кеше иткән җирне
Кем сата?!

Җир эшкәрткән, иген иккән
Онытылмый.
Җир — Ана. Ә Ана ул
Сатылмый.

***Өйрәтәләр бүген:***
Заманалар авыр, көчле бул,
Усалларга усал, үчле бул!
Кыю, үткен сүзле, тешле бул,
Мал кадерен белер эшче бул!

***Өйрәтмиләр бүген:***
Яхшыларга карап яхшы бул,
Акыллы бул, сабыр, тыйнак бул!
Ата-анаң, бабаң шикелле,
Ихтирамга лаек кеше бул!

## ҖИТМИ

«Җитми»ләрне җиткерергә
Вакыт җитеп бетми...

*Ф.Яруллин*

Табигатьтә бар да җитеш,
Күпне өмет итми.
Кешеләргә генә җирдә
Гел нәрсәдер җитми.

Кемнәргәдер эчәр суы
Йә икмәге җитми.
Саф һавалы туган ягы
Истән чыгып бетми.

Кемгә акча, кемгә чүпрәк,
Кемгәдер җир җитми.
Качак булып куылулар,
Кан коюлар бетми.

Ил башында торганнарга
Уйлап эшләү җитми.
Адым саен ялгышулар,
Башка сыеп бетми.

Үрнәк булган гаиләдә дә
Нидер җитеп бетми.
Әти-әниле ятимнәр
Күз алдыннан китми.

Җитми акыл, җитми намус,
Бик күп нәрсә җитми.
«Җитми»ләр җитәр иде дә,
Кеше булу җитми.

**МАЛ КОЛЫ**

Дөнья малы — дуңгыз каны.

*Татар халык әйтеме*

Малы барлар өстен һәрчак,
Малы барның даны бар.
Хәләл малмы, хәрам малмы,
Анда әйбер җаны бар.

Шушы җан кеше күңелен
Үзенчә җайлый, бора.
«Мал малны таба, тырыш!» — дип,
Туктаусыз тукып тора.

Тырыша-тырмаша торгач,
Уңайлыклар шәйләнә.
Чама хисен белмәгәннәр
Мал колына әйләнә.

Кол булдыңмы, намус, вөждан
Читкә алып ташлана.
Бер-береңне рәнҗетүләр,
Алдау, талау башлана.

Ярый әле дөнья малын
Күтәреп китеп булмый.
Алырлар иде югыйсә,
Җирдә бернәрсә купмый.

Аз да җитә, күп тә бетә,
Мал диеп гомер үтә.
Ярый, үлгәч мал кирәкми,
Өч аршын җир дә җитә.

**ГАЕПЛӘРЛӘР...**

Торабыз да үткәннәрне,
Әтиләрне тиргибез.
Җитмеш ел буена нигә
Ялгыш яшәгән, дибез.

Кем белә, безне дә шулай
Еллар үткәч сөйләрләр:
«Дөрес яшәмәгәннәр», — дип
Гаепләрләр, сүгәрләр.

**САЙЛЫЙБЫЗ**

Сайлау бара. Югарыга
Депутатлар сайлыйбыз.
Араларыннан иң шәбен —
Иң телчәнен сайлыйбыз.

Сайлыйбыз кемдә акча күп,
Акмаса да йә тамар,
Безнең ише юньсезләргә
Иң кулай юлны табар.

Сайлыйбыз картын йә яшен,
Йә зур эш йөртүчесен.
Үз мәнфәгатен кайгыртып,
Җан атып йөрүчесен.

Сайлыйбыз кем кемгә якын,
Кемдә кемнәр кайгысы.
Бер мандатка күпме кеше,
Яклар безне кайсысы?

Сайлыйбыз да бер мәнсезен,
Акыл-киңәш даулыйбыз.
Үзебезнең юләрлекне
Яши-яши аңлыйбыз.

**ШИГЫРЬ ЯЗГАН ИДЕМ...**

Шигырь язган идем унбер яшьтә,
Сабакташлар, укып, көлделәр:
«...Без белмәгән берәр шагыйрьнекен
Чәлдергәндер әле», — диделәр.

Шигырь язган идем унсигездә,
«Гашыйк булгандыр бу», — диделәр.
Таныш кызлар: «Кем соң илһамчысы,
Мин түгелме?» — диеп йөрделәр.

Шигырь язган идем утызларда,

Кыйнадылар, тәнкыйтьләделәр:
«Фикереӊ сай, шулай да яз әйдә,
Гонорары булыр», — диделәр.

Шигырь язган идем кырык яшьтә,
Мактадылар, күккә чөйделәр.
«Тырыша торгач, булдырган бит малай,
Дүрт юл шигырь язган», — диделәр.

Шигырь язган идем өлкәнәйгәч,
Миңа карап гаҗәпләнделәр.
Аннан кызгандылар: «Моңарга да
Бала акылы кергән», — диделәр.

**КАДЕРЛЕ БҮЛӘК**

Беркөн күршем хатынына
Айлы алка бүләк иткән.
Сокланырлык, көнләшерлек
Бик кыйммәтле нәрсә икән.

Кояшлысын, йолдызлысын
Мин дә шулай алып бирсәм,
Күршеңне дә уздырдың, дип,
Ничек сөенер иде иркәм.

Кояш кайнар, йолдыз ерак...
Бу уемнан кире китәм.
Иң кадерле, иң кыйммәтле
Йөрәгемне бүләк итәм.

Май ахыры. Карлар ява.
Салкынаеп китте һава.
Көйсез кияү сыман һәр яз
Шулай җүләрләнеп ала.

Гаҗәп түгел, кыш дип тормый,
Тик торганда яңгыр ява.
Табигатьнең дә кайчакта
Акыл ягы безнең чама.

**МӘК ОРЛЫГЫ ЧӘЧТЕМ ЯЛГЫШ КЫНА**

Мәк орлыгы чәчтем ялгыш кына,
Бакчам гөлгә күмелер инде.
Кем уйлаган, сөйгән чәчәкләрем
Зыян китерер дип беркөнне.

Йөрегәнмен икән юкка гына,
Яратам дип шушы мут гөлне.
Мәк башына кызыгып йөрүчеләр
Тартып алды минем иркемне.

Таптап түтәлләрне, кочак-кочак
Җыеп, капчыкларга салдылар.
Мәкләремне түгел, йөрәгемне
Әйтерсең лә тартып алдылар.

Наркобизнес өчен бары чимал
Үстергәнмен икән, сизмәдем
Ялгыштым шул, сөеп шул гөлләрне
Закон бозганымны белмәдем.

Мәк орлыгы чәчтем, нигә чәчтем?
Уңышларын җыялмам инде.
Үзем өчен генә чәчкән идем.
Бәлки, гафу итәрсез мине?!

Укытучы хисап тота.
Борчулы бераз йөзе.
— Классның йөз проценты
Өлгерми калды, — диде.

Бу җаваптан директорның
Күзе маңгайга менде.
Дөресен әйтсәк, бу класста
Бер бала укый иде.

**ТАБИГАТЬТӘ НАЧАР ЧАК ЮК**

У природы нет плохой погоды
*Рус халык әйтеме*

Кирәксә-кирәкмәсә дә,
Сүзне шуннан башлыйбыз:
Йә яңгыр дип, йә аяз дип,
Каргап, тиргәп ташлыйбыз.

Эссе булса, яңгыр көтеп,
Яңгыр яуса — кояшын.
Сүз юктан сүз булсын дип тә
Кайчак әйтеп куясың.

Ни хәлдә дә табигатьнең
Булмый начар һавасы.
Сөйлибез еш бары шуңа:
Без — табигать баласы.

**ХАТЫН-КЫЗЛАР — ГҮЗӘЛ ЗАТЛАР**

Хатын-кызлар, гүзәл затлар,
Сез, — дип яна ир-атлар.
Әле ярый сез бар янда,
Юкса безне кем яклар?

Аек кайткан чаклар бар,
Баеп кайткан чаклар бар.
Мондый чакта айдай балкып
Каршы ала кем? Алар.

Салып кайткан чаклар бар,
Егылып кайткан чаклар бар.
Андый чакта черки булып
Күзгә керә кем? Алар.

Соңлап кайткан чаклар бар,

Кайтмый калган чаклар бар.
Гөнаһ юк та, ә барыбер
Тиргәшергә сәбәп бар.

Ни хәлдә дә без — ирләр,
Күңелебез тулы моң-зар.
Көлдерүче, бөлдерүче
Ярый хатын-кызлар бар.
Рәхмәт! Сез, гүзәл зат бар.

**ТУГАН КӨН**

Күкләргә чөеп мактыйлар.
Нигә болай дисәм,
Шулай тиеш, ул кешенең
Туган көне икән.

Урам тулы этләр «туе».
Булалмый кем дә хуҗа.
Авыл башлыгы да хәтта
Читтән әйләнеп уза.

Җыелышларда зарланып
Сөйлибез кыза-кыза:
— Кая карый бу түрәләр,
Кем монда тәртип боза?!

Ну бу этләр! Алар белән
Күрәбез күпме нужа.
Кызганыч: бүген без түгел,
Ә этләр безгә хуҗа.

**КАБАТЛАНА ШУЛ ХАТАМ**

Авырыймын да еш кына,
Ах-вах килеп йөримен.
Имгәк аяк аста, диләр,
Ник сакланмадым, димен.

Савыгу белән онытам,
Тирләп-пешеп чабамын.
Чабып йөри торгач, кинәт
Тагын килеп кабамын.

Аннан янә уфтанамын:
— Ник сакланмадым икән?!
Бу юлы исән котылсам,
Алай эшләмәм бүтән.

Гомер буе менә шулай
Кабатлана бу хатам.
Терелгәнгә атна да юк,
Тагын авырып ятам.

**ТӨЗӘЛМИ СИНЕҢ ХОЛЫК**

*(Шаяру)*

Төн җитүгә югаласың,
Кайтасың иртән генә.
Шуның хакында югыйсә
Сөйләштек кичә генә.

Кайтасың да, шыпырт кына
Күзгә карап көтәсең.
Беләсең, балалар хакына
Минем гафу итәсен.

Гаҗәпләнәләр алар да
Күреп синең юклыкны.
Күтәралмый күңелләре
Мондый донжуанлыкны.

Бүген дә чыгып сызгансың.
Төзәлми синең холык.
Алтыдагы алтмышка, дип
Белми әйтмәгән халык.

Дуслар әйтә: «Ку да чыгар!»
Киңәш шәп тә... Нишләем?
Ни әйтсәң дә бергә торган
Песием шул, пескәем.

**МӘСГУТ ИМАШЕВКА**

Көчле ихтыярың, бар илһамың,
Җырларыңда үз тавышың, моңың.
«Саубуллашу вальсы»ң хәтерләтә
Малай чакның кыңгыраулар чыңын.

Эшләрең бар телгә алып сөйләр,
Һәм милләт күгендә токкан даның.
Остазы син, дусты, киңәшчесе
Казанда да Барда татарының.

Еракларда гомер кичерсәң дә,
Туган якка тарта күңелең, җаның.
Әнкәң кабере торган изге җирдә
Үзгәдер шул моңы каеннарның.

Сагышланмыйк әле каеннар дип,
Таныш безгә күптән алар хәле.
Янып, яшьнәп иҗат ялкынында
Яшик әле, җырлап яшик әле.

**ЛУИЗА БАТЫР-БОЛГАРИГА**

Җан тартумы,
Кан тартумы,
Ничек киләсе иттең?
Җырларың белән халыкның
Күңел түренә үттең.

Саналсаң Батыр кызы дип
Татар-болгар иленең,
Шәҗәрәң бит бер ботагы

Безнең Барда җиренең.

Белмим, нинди фәрештәләр
Көч-куәт иңдерәдер,
Мөгаен, безнең якның да
Моңнарын сеңдерәдер.

Саекмасын иҗат чишмән,
Моң, илһам торсын тулып.
Яшәле татар халкының
Горур былбылы булып.

**ЗӨФӘР ХӘЙРЕТДИНОВКА**

Язасың гади, халыкчан,
Һәр көйнең тәмен белеп.
Моң, сагыш, сөю җырларың
Күңелне ала телеп.

Һәр җырыңа, фәрештә күк,
Яшәү көче өрәсең.
Ходай сине шундый итеп
Яраткандыр, күрәсең.

Җырчы... Көйче... Гади генә
Булмый аңлатып моны.
Шунсы хак: Зөфәрләр барда
Яшәр ул татар моңы.

**ЯШЬ ҖЫРЧЫ ГҮЗӘЛ УРАЗОВАГА**

Рәхмәт, сеңлем, концертыңны
Килгән иде карыйсы.
Тыңладым да сөенеп куйдым,
Җырларың шәп, ярыйсы.

Алда әле сыналасың,
Биек үрләр аласың.
Тирбәтер үз дулкынында
Казан — моңнар каласы.

Ни хәлдә дә син иң элек —
Безнең якның баласы.
Төп маршрутың булып калсын
Казан — Барда арасы.

Үз җырыңның, үз юлыңның
Өметле табыласы.
Йолдыз чире генә берүк
Булмасын кагыласы.

**ПРОКУРАТУРА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ**

Хезмәтегез алыштыргысыз, беләм.
Чагыштырып карыйм башка эш белән.

Һәрбер эшнең үз авырлыгы... төсе...
Сезнең йөкне тарта алмый күп кеше.

Керә сезгә олысы һәм кечесе,
Эшсезе йә бик зур эш йөртүчесе.

Аздыр үз теләге белән килгәннәр,
Килә гаепле йә кимсетелгәннәр.

Эш йөртәсез статьяларга бәйләп,
Шуңадыр, нәтиҗәсе була әйбәт.

Тәртип бозып сезгә кергән азмы соң?!
Ходаем, дим, сезгә керергә язмасын.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНА

Сезнең хезмәт гаҗәеп, ис китмәле.
Хәтерләтә көмеш сулы чишмәне.
Саф чишмәдәй чылтырап торсагыз гел,
Булырбыз сау һәм югалмас туган тел.

Тел күрке — сүз. Сүз кыйммәтен беләсез.
Шуңа дәресне шәп төшендерәсез.
Күрерсез иң элек эш нәтиҗәсен,
Сөйсә укучы китапны — белем хәзинәсен.

Төшендерәсез: китап алга тартыр.
Күп укыганнар гына бәхет татыр.
Бала күңелен яулау белән көчле сез.
Мактауга, яклауга лаек кеше сез.

## МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ

Кайгыда да, шатлыкта да
Җыр-моң кирәк кешегә.
Җитәкчегә, игенчегә,
Терлекчегә, эшчегә.

Җыр, бию, китап сөймәгән
Татар татар буламы?
Юк шуңа да бәйрәмнәрнең
Сездән башка узганы.

Милләт язмышын кайгыртып
Йөрисез янып-көеп.
Сөйли сезне кайберәүләр,
Яши, дип, җырлап-биеп.

Халык күңелен дәвалауда
Гел табиблар төсле сез.
Мәдәниятле, сәнгатьле,
Рухиятле кеше сез.

## ГОМЕР КӨЗЕНӘ КЕРЕП БАРУЧЫЛАРГА

Уфтанма, зарланма әле,
Үтә, дип гомеркәең.
Көзләргә иртәрәк бугай,
Бусы — җиләкле җәең.

Коела җиләкләрем, дип
Төшмәсен күңелкәең.

Җәйләрдән соң язлар килми,
Тормыш бу, сеңелкәем.

**БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ!**

*Яшь парларга*

Сезнең бүген иң кадерле,
Гүзәл яшьлек туегыз.
Табыштыгыз, кавыштыгыз,
Уртак булсын уегыз!

Дус-туганны сөендереп
Тату гаилә корыгыз!
Бер-берешне ярты сүздән
Аңлый торган булыгыз!

Тормыш түгел алсу алма,
Булыр төрле чагыгыз.
Кыен хәлдән чыгу юлын
Икәү бергә табыгыз!

Кодалар, дуслар, туганнар —
Булырбыз терәгегез.
Таза-сау, бәхетле булыгыз,
Шул иң зур теләгебез.

**ГАИЛӘ КОРУЧЫ ЯШЬ ПАРЛАРГА**

Кияү! Кәләш!
Уйлап ярәш.
Бер була яшьлек туе.
Сүндерми сөю учагын
Саклагыз гомер буе!

**ҖИЛӘК АЙЛАРЫНДА ТУГАН ДУСКА**

Җиләк айларында тугангамы,
Җылы һәм ягымлы күңелең.
Тик язмышлар гына искәрттеләр
Яшәүләрнең җиләк түгелен.

Җиләк айларында туганга да
Гел елмаймый бәхет кояшы.
Яши генә башлыйм дигән чакта
Тормыш рәнҗетүен тоясың.

Җиләкле җәй көттерепләр килә,
Үтеп китүе тиз икән.
Чәчәкле җәй соңы язлар түгел,
Сары сагыш сарган көз икән.

**ҖЫРЧЫ ЛИЛИЯ БИКТИМЕРОВАГА**

Ятимлекләр, ачы язмыш
Җаныңа кагылганмы?
Инде килеп йөрәгеңнән
Моң булып агыламы?

Ни хәлдә дә син иң элек
Безнең якның баласы.
Димәк, көч, илһам өстәгән
Табигате, һавасы.

Рәхмәт, сеңлем! Җырларың шәп,
Ала күңелне телеп.
Тормышың да җырың төсле
Матур булсын иң элек.

Әйтергә язсын беркөнне
Яратып, ихлас сөеп:
Сәнгать күгендә тагын бер
Йолдыз кабынды, диеп.

**ХЕЗМӘТТӘШЕМӘ**

Әле кайчан без утырган идек
Җырлап юбилеең түрендә.
Онытылмас бу гүзәл мизгелләр
Күз алдында тора бүген дә.

Нәкъ бер яшькә яшьрәк идек ул чак,
Ак чәчләр дә, бәлки, аз булган.
Дөнья куып, эш дип янып-көеп,
Гомер уза икән ул, туган.

Шагыйрьләрчә әйтсәк: гомер-йомгак
Сүтеләсе шактый сүтелде.
Тик хыяллар һаман ап-ак һәм саф,
Ноябрьнең кары шикелле.

Зарланмыйбыз гомер узуларга,
Һәр туар таң — көрәш, яңалык.
Чыныгып үскән авыл малаена
Бирсен генә Ходай тазалык.

**САЛАВАТ ФӘТХЕТДИНОВКА**

Әле кайчан яшь бер җырчы булып,
Күңелен ачып йөрсәң халыкның,
Бүген күрәм: сәнгать күкләрендә
Якты йолдыз булып калыктың.

Йолдыз якты якын булса гына.
Ерак йолдыз кемгә кирәк соң?!
Якын итеп, якташ халык итеп
Күңелләргә үттең салып моң.

Татар барда татар иле яшәр,
Салаваты барда — яшәр моң.
Моңы сүнмәс Сәйдәшләре булган,
Илһамнары булган халыкның.

**СССРНЫҢ ҺӘМ РӘСӘЙНЕҢ СПОРТ МАСТЕРЫ, АВЫЛДАШЫМ ГАБДУЛЛА БАЛТАЕВНЫҢ ИСТӘЛЕГЕНӘ**

Сокланырлык иде гомер юлың,
Булдың кешелекле һәм тыйнак.

Чаңгы ярышымы, йөгерүме...
Атылып кала идең ук сымак.

Күрәшче ир-атлар иртә китә,
Бу сүзләрдә хаклык бар, димәк.
Егылдың һәм киттең... ярышларда
Йөрәге ярылып үлгән ат сымак.

**КЕШЕ КИТӘ — ЭШЕ, ҖЫРЫ КАЛА**

*Җырчы Әхмәтзыя Илкәевнең якты истәлегенә*

Кеше китә — эше, җыры кала.
Җыр эченә сагыш, моң сыя.
Моңлы затлар бәгырьләрне телеп
Мәңгелеккә күчә дә куя.

Әле кайчан,
Янбикәм, дип өзелеп,
Чапан җиңнәреңне җыя-җыя,
Җырлап торган чагың хәтерләргә
Уелып кына калды, Әхмәтзыя.

Туган-үскән җирдән, җан дуслардан,
Фани дөньялардан кем туя?
Туганнарың калды, сөйгән ярың,
Балаларың җыеп бер оя.

Үрнәк ата идең син аларга,
Тормыш таянычы, таш кыя.
Яши генә башлыйм дигән чакта,
Язмыш кылычы кисә дә куя.

Һай кыска шул, кыска гомер юлы,
Шунысы бигрәк җаннарны кыя.
Иҗатыңның нәкъ кыл уртасында
Киттең, ятим иттең, Әхмәтзыя.

**АВЫЛДАШЫМ**
**НӘКЫЙП ГАЛИЕВ ИСТӘЛЕГЕНӘ**

Арабыздан китә берәм-берәм
Изге җаннар — яхшы кешеләр.
Малай чакта бергә уйнап үскән
Авылдашлар — якын күршеләр.

Менә бүген дә бер дустыбызның
Җыйналыштык соңгы туена.
Болай кинәт иртә китүләрең
Кермәгән дә иде уема.

Булдың гади, тыйнак һәм намуслы.
Акыллы зат идең тумыштан.
Гомерең генә бары кыска булды,
Узмышлар юк, ахры, язмыштан.

Яши генә башлыйм дигән чакта,
Китә дә югала ник ирләр?
Бездән торса, мең ел бирер идек,
Һай кыска шул, кыска гомерләр.

## ДӨНЬЯДАН ВАКЫТСЫЗ КИТҮЧЕГӘ

Очты җаның,
Фани гәүдәң
Кул сузымы ара.
Әрнү тулы
Күңелләрдә
Төзәлмәслек яра.

## УКЫТУЧЫМ

*Олы җанлы укытучыларыма багышлана*

Әйтелмичә калган яшьлек белән
Күпме җылы сүзләр күңелдә.
Укытучым! Искә төшәсез дә,
Кызарып куямын әле дә.

Рәнҗеткәнбез кайчак юктан гына,
Җаныгызны азмы кыйганбыз.
Дәресләрне белмәү белән бергә
Кире дә, шаян да булганбыз.

Нык булгандыр сабыр канатыгыз,
Бер дә ачуланмый түзгәнсез.
Юләр чаклар булган, елар чаклар.
Безгә кушылып Сез дә көлгәнсез.

Бик еш кайтам хәзер хәтер буйлап
Балачакка — гомер языма.
Рәхмәт әйтәм шунда барысы өчен,
Ураганга сөю-назыңа.

Күптән инде Сез лаеклы ялда.
Тик һаман да мөлаем, яшьсез.
Тәрбияче, киңәшче, дус булып
Йөрәк түрләрендә яшисез.

### ЭЧТӘЛЕК


Һидаятьле Идият. *Рәшит Ягъфәров* ..................

**Барда җире — гүзәл Гәйнә иле**

Барда җире ................................
Без кем? ..................................
Горурлык ..................................
Барда белән Арча арасы ..........................
Сынар өчен яраткандыр... ........................
Барда ягы ..................................
Үкенмим ..................................
Туган җир ..................................
Баш сау булса ...............................
Авыл җире .................................
Туган як ..................................
Җәйге авыл .................................
Поезд чаба туган якка ...........................
Китү... кайту... ...............................
Тугыз бала үстек ..............................
Кайтам әле .................................
Сабан туе бүген ..............................
Мәхәббәт чишмәсе ............................
Март ....................................
Кычытканнар ...............................
Кайтсам туган якка ............................
Карлар ява .................................
Авылым таулары ..............................

**Тормыш мизгелләре**


Ашыгабыз .................................
Күзге моң .................................
Рәссам бүләге ...............................
Көмеш кыңгырау .............................
«Елап туа кеше...» .............................
Таныш хәл .................................
«Узып бара...» ...............................
«Кеше гомере...» ..............................
Әйләнәм дә кайтам үткәннәргә ......................
«Уфтанмыйк та...» .............................
«Тормыш — кросс...» ...........................
Моңсу халәт ................................
«Гасыр алмашына...» ...........................
«Гомер-йомгак...» .............................
Иң бәхетле чак икән ............................
Саубуллашу ................................
Туган көн .................................
Туй күлмәге ................................
Искә алам .................................
Әни кирәк .................................
Яхшы кешеләр ешрак кагыла .......................
Без бу җирнең әрсез кунаклары .....................
Шундый тәртип ..............................
Сабый кайтты өйгә ............................
Олуг шагыйрьләрне укыйм ........................
«Сельсовет түгел...» ............................
Әфганстан — йөрәк ярам ........................
Чир китә, гадәт китми ..........................
Йөрәкне уйлар талый ...........................
Әманәт ...................................
Искә төшә әнкәй сүзләре .........................
«Гомер кыска...» ..............................
«Бер мичкә балны...» ...........................
Басу капкасы ................................
Тормыш — ормыш ............................
Язмышымда ялгышмам ..........................
Кеше булыйк! ...............................
Азан моңы .................................
«Милләтне милләт итүче...» ........................
«Ак күлмәкләр киям сирәк...» ......................
«Яхшылык иткән кешегә...» .......................
«Яхшы адәм бик тиз китә...» .......................
Бөркет һәм тавык .............................
Аз һәм күп .................................
Ятимлектә кем гаепле? ..........................
«Эш сөйгәннәр гомер буе...» .......................
Бары бер сүз ...............................
Таркалган хуҗалыкта ...........................
Шкафымда тора Коръән .........................
Җир — Ана ................................
«Өйрәтәләр...» ...............................
Җитми ...................................
Мал колы .................................
Гаепләрләр .................................
Сайлыйбыз .................................
Шигырь язган идем... ...........................
Кадерле бүләк ...............................
«Май ахыры...» ...............................
Мәк орлыгы чәчтем ялгыш кына .....................
«Укытучы хисап тота...» ..........................
Табигатьтә начар чак юк .........................
Хатын-кызлар — гүзәл затлар ......................
Туган көн .................................
«Урам тулы этләр...» ............................
Кабатлана шул хатам ...........................
Төзәлми синең холык ...........................


**Багышлаулар**


Мәсгут Имашевка .............................
Луиза Батыр-Болгарига ..........................
Зөфәр Хәйретдиновка ...........................
Яшь җырчы Гүзәл Уразовага .......................
Прокуратура хезмәткәрләренә ......................
Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ................
Мәдәният хезмәткәрләренә .......................
Гомер көзенә кереп баручыларга .....................
Бәхетле булыгыз! .............................
Гаилә коручы яшь парларга ........................

Җиләк айларында туган дуска ......................
Җырчы Лилия Биктимеровага ......................
Хезмәттәшемә ...............................
Салават Фәтхетдиновка ..........................
Габдулла Балтаев истәлегенә .......................
Кеше китә — эше, җыры кала ......................
Авылдашым Нәкыйп Галиев истәлегенә ................
Дөньядан вакытсыз китүчегә .......................
Укытучым .................................

Заказное издание

**Аширов** Идият Мукимович

**МЕЛОДИИ УРАЛА**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Заказ басма

**Әширов** Идият Мокыйм улы

**УРАЛ АҺӘҢНӘРЕ**

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов.* Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова.* Корректоры *Г.Г.Гарифуллина.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.09.2007. Форматы 70г100 1/32. Офсет кәгазе. «Lazurski» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,9. Шартлы буяу-оттиск 4,22. Нәшер-хисап табагы 3,09. Тиражы 1000 д. Заказ С-1193. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru. Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.